

14 ноябрьдә, Халыкара толерантлык коне алдыннан (16 ноябрь) Саранскнын №7 Л.Н.Толстой исемен йорткән китапханәдә «Республика газеталарында татар доньясы» дигән этнокичә vтте. Чарада Саранск шәһәре 38нче мәктәпнен 9 «Г» сыйныф укучылары һәм олкәннәр катнашты. «Тынычлыкка һәм татулыкка китап белән бергә» һәм «Мордовия Республикасы газеталарында татар доньясы» исемле тирән эчтәлекле ике китап кvргәзмәсе кичә темасын тулыландырды.     Мордовия Республикасы - кvпмил-ләтле регион. Анын территориясендә торле халык вәкилләре яши: әрмәннәр, чуашлар, марилар, грузиннар һәм башка милләт халкы. Тик республиканын милли составында ин кvпләрен руслар, мордвалар һәм татарлар тәшкил итә. Алар бергә-бергә дус яши. Бу чара да шуна дәлил.




Китапханә модире Наталья Юрьевна Шумаева чыгышында кунакларга безнен заманда торле милли мәдәниятләр вәкилләренә карата толерантлыкнын әһәмияте, шулай ук дәvләт тозvче тел буларак рус телен һәм туган милли телләрне яклау, саклау чаралары турында сойләде. Әйтеп китәргә кирәк, Саранск шәһәре Л.Н.Толстой исемен йорткән 7нче номерлы китапханә филиалын оч дистә елга якын Наталья Юрьевна Шумаева житәкли. Анын карамагында Регина Рифат кызы Юсупова, Елена Николаевна Черакшева, Наталья Алексеевна Трясучкина китапханәчеләр тырышып хезмәт итәләр. Барысы да чарада актив катнаштылар. Регина Рифат кызы Юсупова тамашачыларны татар телендә сәламләде һәм Габдулла Тукайнын татар һәм рус телләрендә «Туган тел» шигырен укыды. Аннары кичәне алып баручылар - Елена Николаевна Черакшева, Наталья Алексеевна Трясучкина Мордовиядә яшәvче татарлар, аларнын мәдәнияте, әдәбияты, милли гореф - гадәтләре турында, презентация кулланып, хәбәр иттеләр. Китапханәчеләр Россиянен Атказанган журналисты, Мордовиянен халык шагыйре, «Юлдаш» газетасынын баш мохәррире Камиль Тангалычевнын «Соловьи» һәм «На Родине»шигырьләрен укыдылар. Татар темасы республика газеталарында, аерым алганда «Юлдаш» ижтимагый-сәяси газетасы турында яше-карты зур кызыксыну белән

тынлады. 

Республиканын татар доньясы «Юлдаш» («Спутник») газетасында кинрәк тәкъдим ителгәнгә кvрә, алып баручылар сvзне Мордовиянен атказанган массакvләм мәгълvмат чаралары хезмәткәре, «Юлдаш» газетасы хәбәрчесе Наилә Хәлил кызы Насыровага бирделәр. Ул газетанын vткәне һәм бvгенгесе, яктыртылган темалар, хезмәткәрләре турында сойләде. Шулай ук Ркаил Зәйдулла тәржемәсендә Камиль Тангалычев шигырьләрен укыды, китапханәгә авторнын имзасы белән нәшер ителгән китапларын бvләк итте.

Этнокичәнен йомгаклау олешендә матур концерт тынладык. Тамашачыларга «Уйна, гармун» район һәм республика конкурслары лауреаты, Тvбән Новгород шәһәрендә тобәкара фестивальләрдә катнашучы «Саранск шәһәр округы мәдәният сарае» гармунчысы Зыя Максутов, Саранск шәһәре мәдәният сарае солистлары – Надежда Бабенкова, Альмира Максутова, Каюм Апарин тамашачыларга vзләренен ижатларын бvләк иттеләр. Алар рус һәм татар телләрендә лирик жырлар, такмаклар башкардылар. Тамашачылар алкышларны кызганмады! Этнокичә кунаклары татар мәдәнияте доньясына һәм монлы татар койләренә чумдылар.

Очрашу укучылар һәм олкәннәрнен милли тәм-томнар белән дусларча бергәләп чәй эчv белән тәмамланды.

**Наилә НАСЫРОВА**